СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 18, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 18 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366) 94-2-37, факс (84366) 94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Апаз авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 29 » сентябрь 2017 ел** **№ 81**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге Советы карар бирде: "2018 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 380 сум күләмендә (түләү күләме 190 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

1. Апаз авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсәләсе буенча җирле референдум уздыруны 2017 елның 19 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2018 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 380 сум күләмендә (түләү күләме 190 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- вак таш сатып алу, юл-урам челтәрендәге вак таш һәм юл өслеген

төзекләндерү буенча хезмәтләр күрсәтү: Апаз авылы (Тукай урамы (3 нче йорттан 14 нче йортка кадәр, Совет урамы, 49-нчы йорт янындагы тыкрык белән (370 м) (вак таш), Базар урамы (21 нче йорттан 45 йортка кадәр (380 м) (вак таш), Гагарин урамы, 32 йорттан алып 46 нчы йортка кадәр янәшәдәге юл белән Совет ур., 18а (балалар бакчасы) (420 м); Каратай авылы (Каратай авылына килү юлы) (вак таш); Пөшәңгәр авылы (Әһлиуллин урамы (1 нче йорттан 7 нче йортка кадәр (вак таш); нигез салу : Нагорный урамы (1 нче йорттан 35 нче йортка кадәр (чуерташ); Миржәм авылы (Н.Сафин урамы (12 нче йорттан 23 нче йортка кадәр (вак таш); Кзыл Игенче авылы (5 нче йорттан 6 нчы йортка кадәр) (вак таш).

2. Күмү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:

- торак пунктлардагы зиратларны карап тоту өчен инструментлар (бензопила, чапкыч) сатып алу: Апаз авылы, Каратай авылы, Пөшәңгәр авылы, Миржәм авылы, Хәсәншәех авылы;
- Хәсәншәех авылында җирләү өчен кирәк-яраклар алу;
- Хәсәншәех авылы зираты территориясендә агачларны санитар кисү.

3. Җирлек территориясендә төзекләндерү эшләрен оештыру:

- торак пунктларда аншлаглар әзерләү һәм урнаштыру: Апаз авылы, Хәсәншәех авылы, Миржәм авылы.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе                юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 19 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Хәсәншәех авылы, Космонавтлар урамы, 20 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 42А йорты, Чапаев урамы, 33 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Миржәм авылы, Н.Сафин урамы, 36 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы                Р.Ш.Садиков

СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003056